Azatlıq Radiosı

ЯҢАЛЫКЛАР

# Краснодарда дрон һөҗүменнән соң тумышы белән Уфадан булган 16 яшьлек кыз һәлак булган

әле генә




Иллюстратив фото

**Туганнары кызны Уфага алып кайтып җирләү өчен акча җыю игълан иткән**

Фаҗига 24 август көнне була. Ул көнне Краснодарга дроннар һөҗүм итә. Һәлак булучылар арасында 16 яшьлек кыз да була.

Туганнары сүзләренчә, җәй көнне ул авыр яшүсмерләр өчен булдырылган балалар тернәкләндерү үзәгендә яшәгән. Mkset Telegram каналы язуынча, фаҗигадән соң туганнарына мәетне Уфага җибәрергә вәгъдә итсәләр, соңрак бары тие 50 мең сум гына бүлеп бирә алачакларын хәбәр иткәннәр.

Һәлак булган кызның туганнары әйтүенчә, мәетне Уфага кайтару өчен транспорт чыгымнары 125 мең сум тирәсе тәшкил итә. Хәзерге вакытта кызның апасы моның өчен акча җыю игълан иткән.

24 августта Краснодар төбәгендә дроннар һөҗүме нәтиҗәсендә ике бала һәлак булуы турында төбәк губернаторы **Вениамин Кондратьев** белдергән иде. Ул дрон калдыкларының шәхси балалар үзәгенә төшүен әйтте. Тагын җиде бала җәрәхәтләнгәне белдерелде.

🛑 **Русиядә Азатлык Радиосы сайты томаланды, нишләргә? Безнең кулланма.**
🌐 **Безнең Telegram каналына да кушылырга онытмагыз!**

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар саклanган